**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«20» август 2019 ел　　　　Сәмәкәй　　　　№ 15

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү ХАКында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча фикер алышуда Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге халкының катнашу хокукларын саклау максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсе 4 өлешенә, Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында 2019 елның 22 августыннан да соңга калмыйча урнаштырырга .

3. Билгеләргә:

- халык тыңлауларын бер көндә үткәрергә;
- халык тыңлауларын үтәкәрү вакытын: 2019 елның 20 сентябрендә 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урынын: ТР, Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге, А.Биктимеров урамы, 44 йорты (Сәмәкәй авыл мәдәният бинасы)
- проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү, халык тыңлауларында катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән гаризалар бирү өчен адрес: Сәмәкәй авылы, А.Биктимеров урамы, 46 йорт, (Сәмәкәй авыл җирлеге бинасы) эш көннәрендә-8.00

дән 16.00 сәгатькә кадәр) бирергә кирәк,  2019 елның 22 августыннан 18 сентябренә кадәр).

- халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2019 елның 18 сентябренә кадәр.

4. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын  үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Сәмәкәй авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары,
№ 2 сайлау округыннан депутат М.Г.Галимзянов